# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 5 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында" 2011 елның 10 октябрендәге 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:

а) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Җиңел такси буларак куллану күздә тотыла торган транспорт чараларын мөрәҗәгать итүченең нинди хокукый нигездә биләвенә карамастан, бер транспорт чарасына карата бер генә рөхсәт бирелергә мөмкин.";

б) 3 өлештә "срогын," сүзеннән соң "гариза бирү тәртибен," сүзләрен өстәргә;

2) 4 статьяның 2 өлешендәге 2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 5 статьяда:

а) статья исемендә "тикшереп тору" сүзләрен "региональ дәүләт тикшереп торуы" сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Федераль законның 9 статьясындагы $1^4$ һәм 16 өлешләрендә һәм әлеге Законның 4 статьясында билгеләнгән таләпләрне пассажирлар йөртүчеләр (багаж ташучылар) тарафыннан үтәүне региональ дәүләт тикшереп торуы вәкаләтле орган

тарафыннан гамәлгә ашырыла (күрсәтелгән таләпләрне үтәүне турыдан-туры җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу процессында тикшереп торудан гайре).";

в) 10 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"10. Федераль законның 9 статьясындагы $1^4$ һәм 16 өлешләрендә һәм әлеге Законның 4 статьясында билгеләнгән таләпләрне пассажирлар йөртүчеләр (багаж ташучылар) тарафыннан үтәүне региональ дәүләт тикшереп торуының әлеге статья белән җайга салынмаган тәртибенә карата, Федераль законның 9 статьясында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, "Дәүләт тикшереп торуын (күзәтчелеген) һәм муниципаль тикшереп торуны гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында" 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2012 елның 20 июле
№ 60-ТРЗ